# КЕРЕШ СҮЗ

Милләтебезнең язмышы кыл өстендә.
*А. Гыйләҗев*

«Сайланма әсәрләр»нең 5 нче томына Аяз Гыйләҗевнең «Яра» (1984, 1988) повесте, үзгәртеп кору һәм хәбәрдарлык (сүз иреге) чорына караган көндәлекләре, хатлары кертелде.

1985–1991 еллар СССР гражданнары өчен зур ышанычлар һәм шул ук вакытта коточкыч фаҗигаләр, киләчәккә булган өметләрнең юкка чыгу чоры буларак билгеле. Торгынлык чорында (1964–1985) халыкның күпчелеге өчен уртак һәм аңлаешлы булган тормыш стратегияләре формалаша. Кешеләр конкрет тормыш кыйммәтләрен өстен куеп (яхшы машинада йөрү, фатир һәм бакча (дача) сатып алу), бай һәм мул тормышта яшәргә хыялланалар («Җомга көн, кич белән...» (1972–1979), «Әтәч менгән читәнгә» (1979–1980) әсәрләре – моның ачык мисалы). Ләкин шәһәрдә ирешкән уңышлары өчен татар кешесе бик кыйммәт түләргә тиеш була: көннән-көн милли тамырларыннан, бигрәк тә туган теленнән, диненнән, милли яшәү рәвешеннән ераклашкан кешеләр күбәя («Балта кем кулында?» (1988–1989) романы).

80 нче елларда Казанда татар телендә белем бирә торган бары бер мәктәп була, калган мәктәпләрнең күбесендә татар теле дәресләре татарча текстлар укуга гына кайтып кала, кайберләрендә исә бөтенләй укытылмый. Шулай итеп, авылда туып үскән татарларның оныклары туган телләрен белми һәм аңламый, иң куркынычы – бу хәл гадәти күренешкә әверелә. 400 000 татар кешесе яшәгән Казан шәһәрендә исә бу елларда нибары бер мәчет – Мәрҗани мәчете эшли, анда да күбесенчә өлкән яшьтәгеләр йөри.

Совет чорының соңгы елларында, 1989 елгы халык санын алу нәтиҗәләреннән күренгәнчә, татар гаиләләренең кырык проценттан артыгы катнаш була. 1979 елда миллиончы казанлы исемен әтисе – татар, әнисе рус милләтеннән булган малайга бирәләр. Милли тамырларны югалту татар телендә дини һәм дөньяви белем алган өлкәннәрне дә, татар совет мәктәпләрен тәмамлаган урта буынны да борчый. «Сугыш тынган арада...» мәкаләсендә А. Гыйләҗев бу проблема турында менә ничек яза: «Бүгенге көн мәгълүматларына караганда, татар егетләренең кырык про-

центы чит милләт вәкилләренә өйләнсә, татар кызларының кырык ике проценты бүтән милләт егетләрен яр итә. «Азат хатын» журналының соңгы егерме ел эчендәге «хезмәте» шул булды: ул әле Өркет ягыннан, әле Кызыл Ярдан килгән хатларны «интернационализм» үрнәге итеп бастыра килде. «Бер киявем немец, икенчесе белорус! Берсе урыс, икенчесе мукшы» дигән мактанчык хатлар саннан санга күчә килделәр. Кызганыч бәндәләр! Киявең немец икән, синең нәсел җебең шул урында өзелде дигән сүз.

Без – бөек Болгар дәүләтенең, данлы-шанлы тарихыбызның варислары. Тик шуны аңлау, шул якты эз белән горурлану милләт ул-кызларының канына сеңмәгән… Тарихны үзгәртеп булмаса да, тарихка карашны ачыкларга, турыларга һәм рәткә салырга бик вакыт»*.

Язучы татар халкының социализм елларындагы зур югалтулары хакында да ачынып яза: «Милләтебезнең язмышы кыл өстендә. Туган Татарстаныбызда милләтебезнең күкрәк киереп сулавын тәэмин итә алмаганны, башка төбәкләрдә яшәүче кан кардәшләребез турында ни әйтә алыйк?! «Татар» дип ирәеп авыз ачарга курыктык, посып, ярым тавышка яшәргә гадәтләндерделәр. Татар авылларын бетерделәр, колхозларга башка халык яшәгән авылларны катнаштырып, саф татар авылы вәкилләре дә русча гына сөйләшергә өйрәнделәр. Колхоз рәисләренә кадәр стандарт фикер йөртергә, русча гына сөйләргә күнектеләр. Мең еллар дәвамында ярагaн матур, моңлы телебез чит-ят сүзләр белән чүпләнде. Мәктәпләрдә татар телен кимсетеп, аны икенче дәрәҗәле телгә төшерделәр. Әй, саный башласаң, социализм чорында халкыбыз күргән җәбер-җәфаларны, телебез кичергән бәла-казаларны санап бетерерлек түгел! Иманыбыз изелде, динебез мыскылланды, гореф-гадәтләребез үзгәрде»**. Эш белән республика районнарына барганнан соң, язучы әнә шундый нәтиҗәләр ясый һәм аның Мөхәммәт Мәһдиев, Марсель Галиев белән берлектә иҗат иткән «Игелек» исемле очерклар җыентыгы дөнья күрә. Заказ буенча язылган булганга***, китапта әйтелмичә калган фикерләрен А. Гыйләҗев хатларында, көндәлекләрендә һәм яңа әсәре – «Балта кем кулында?» романының «авыл бүлекләре»ндә чагылдыра.

«Шәһәр әлегә татар шәхесләрен белми. Канында, җанында милли рух юк икән, андыйларны мин «ямаулы татарлар» дип атыйм. Ана карыныннан ук Сәйдәш моңнарын, «Ак бүре» әкиятен тыңлап үсмәгән татар беркайчан да чын татар була алмый. Халкы-

---

* А. Гыйләҗевнең шәхси архивы: «Сугыш тынган арада…» (1990. – 6 август).

** *Гыйләҗев А.* Зәй – минем күңелемнең кәгъбәсе // Зәй офыклары. – 1990. – 12 июнь. – № 2. – 2 б.

*** *Мәһдиев М., Гыйләҗев А., Галиев М.* Игелек. – Казан : Китап, 1989. – 650 б.

на мәхәббәт тәрбияләнмәгән кешедән ничек инде милли каһарман чыксын?! Ләкин... Татарның коесы корыган, чишмәсе агышын туктаткан дип әйтергә җыенмыйм. Хәзерге көндә милләтне ныгытырга мөмкинлекләр бар»*, — дип борчылып яза әдип.

1988 елда матбугатта татар теленә өйрәтүнең сыйфаты һәм мәктәпләрдәге реаль икетеллелек мәсьәләсе күтәрелә. Казан халкы тарафыннан иң күп укылган «Вечерняя Казань» газетасында (1988, 27 гыйнвар) чын, реаль икетеллелекне яклап язылган мәкалә дөнья күрә. Язманың авторы — Искәндәр Гыйләҗев (А. Гыйләҗевнең улы) фикеренчә, татар теленә өйрәтүнең алда күрсәтелгән ысулы «урта мәктәп укучысыннан үз халкының мәдәниятен генә түгел, хәтта телен, тарихи тамырларын да белмәүче милли нигилист тәрбияли»**. Казан университеты галимнәре бөтен көчләрен татар теленең статусын үстерүгә юнәлтәләр. Татар теле һәм әдәбияты, тарихы һәм мәдәнияте, 20 нче еллардагыча, төрки халыклар системасына кертеп өйрәнелә башлый. Бу процесска А. Гыйләҗевнең дусты, татар филологиясе, тарихы һәм Көнчыгыш телләре факультетын яңадан ачкан 1989 елдан шул факультетның татар халкы тарихы кафедрасын җитәкләгән Миркасыйм Госманов зур өлеш кертә.

А. Гыйләҗев исә үз чиратында милли мәдәнияттә традицияләр күчемлелеген нәкъ менә язучылар тәэмин итәргә тиеш дип саный: «Элек гасырдан гасырга буыннар бәйләнешы сакланган, төрле формаларда вакыт адымнары бер-берсенә тоташкан булган. Хәзер без кискен борылышлар чоры кичерәбез. Күп вакытта кичәге бүгенгә ярамый дип санайбыз, кичәге гыйбрәтләрне хәтердән чыгарып ыргытабыз. Әнә шул бәйләнешлар, әнә шул вакыт бәйләнеше генә милләтләрне милләт итеп, халыкны бөтен итеп яшәтә, бәйләныш өзелсә, милләт милләт булудан туктый.

Илбасарлар, гадәттә, беренче эш итеп халыкның аңын томалаудан башлыйлар, тарихны кисеп ташларга омтылалар. Кәрим Тинчурин, Галимҗан Ибраһимов, Мәхмүт Галәү, Фәтхи Бурнашларны Сталин тиктәскә генә юк итмәгән ләбаса! Алар белән бергә ул татар халкын да җиргә күмәргә омтылган! Әдәбият-сәнгать ул гади әдәп сакчысы гына түгел, әдәбият-сәнгать вакыт бәйләнешының сакчысы да. Әмирхан Еники, Мөхәммәт Мәһдиев егерменче гасырның иң хәтәр, иң усал елларында милләт бөтенлеге сакчылары булып, мең ел элек салына башлаган хәтер күперенең баганалары булып бастылар»***.

---

* *Гыйләҗев А.* Без бит бәхетсез заман җимешләре (Рәмис Аймәт белән әңгәмә) // Шәһри Казан. – 1989. – 30 сентябрь.

** Республика Татарстан: новейшая история. События. Комментарии. Оценки / авт.-сост. Ф. Мухаметшин, Л. Агеева. – Казань, 2000. – С. 25–26.

*** А. Гыйләҗевнең шәхси архивы: «Сайланып чыккан сүзләр» (1989. – Июнь).

СССРда рухи кыйммәтләр һәм әхлак хакындагы бәхәсләр үзәк матбугат битләрендә дә, ил эчендә дә бара. А. Гыйләҗевнең «Җан авазы»*, «Имән чикләвеге»** мәкаләләре замандашлары арасында зур резонанс уята.

«Үкенечләрнең берсе, актыккысы түгел...» мәкаләсендә (1990) язучының канәгатьләнү хисе белән язганлыгы күренә: «Ниһаять, татар җаны да сталинчыл социализм кысасына сыймый башлады, әле моннан берничә ел элек кенә үткәннәргә — куркып, киләчәккә тулы өметсезлек белән карасак, бүген иреннәребез язылa төште, мәңгегә йомылган дип уйланган авызлардан онытылган, төсләре уңып, кадере калмаган дип саналган сүзләрнең яңача яңгырар көне килде: «шәфкать» дибез, «мәрхәмәтле булырга» өндибез, иманыбызга кире кайтырга чакырабыз. Күзләр як-якка түгел, бер-беребезгә туры карый. Телебезнең гаять зур эчтәлекле, тирән мәгънәгә ия сүзләре кабат күңелебезгә иңә, һәм шул сүзләр бүген үзара мөнәсәбәтләрне билгелиләр. «Игелек», «татулык», «туган телебез», «газиз җиребез» дип әйткән саен, күңелләребезгә яктылык сеңә бара, барыр юлыбыз киртәгә илтеп терәлгән тар сукмактан котылып чыгып, Олы юлга чыгарга омтылабыз! Уйлап карасаң, чәчең үрә торырлык иде бит, валлаһи! Җитмеш ел дәвамында халкыбыз аңында меңеллар эчендә тупланган иманны, гаделлекне, ихласлыкны, өлкәннәргә ихтирамны, туган телгә риясыз мәхәббәтне тәмам җуя яздык»***.

Бу урында шуны да ассызыклап узарга кирәк: үзгәртеп кору чорының беренче елларында әдәбият «этик сугышлар һәм бәхәсләр кыры»на әверелә. Кайбер язучылар коммунистик этикага булган рәсми карашларын яклыйлар (мәсәлән, М. Шатровның «Диктатура совести» (1986) әсәре). А. Рыбаковның «Дети Арбата» романы да укучыларга бик нык тәэсир итә. Күп кенә язучылар фикеренчә, Россия үзенең рухи кыйммәтләрен, рухи ягын югалта бара (В. Астафьевның «Слепой рыбак» (1986) әсәре). 1986–1987 елларда «Новый мир» журналы битләрендә Ч. Айтматовның «Плаха», В. Тендряковның «Покушение на миражи» романнары дөнья күрә. Бу әсәрләрдә рухи кыйммәтләр мәсьәләсе православиегә генә кайтып калмыйча, алар христиан диненә булган заманча мөнәсәбәтне дә (энтузиазм һәм скептицизм кушылмасын) ачык чагылдыра.

Татар әдәбиятында исә А. Гыйләҗев М. Мәһдиевнең шушы чорда дөнья күргән «Бәхилләшү» повестена игътибар итә: «Бәхилләшү» — мәгълүм бер чорның, без яшәгән заманның, әле офык

* *Гыйләҗев А.* Җан авазы (Ибраһим Салаховның «Тайгак кичү» романын укыганнан соң туган фикерләр) // Социалистик Татарстан. – 1989. – 26 февраль.

** *Гыйләҗев А.* Имән чикләвеге // Шәһри Казан. – 1990. – № 15. – 28 ноябрь. – 1–3 б.

*** *Гыйләҗев А.* Без бит бәхетсез заман җимешләре (Рәмис Аймәт белән әңгәмә) // Шәһри Казан. – 1989. – 30 сентябрь.

артында җәйге таң кебек кенә яралып килгән билгесез киләчәк белән хушлашуы ул. Автор, һич читенсенмичә, «Күрегез дә гыйбрәт алыгыз: без әнә шулай яшәдек» дип әйтергә тели. Тавышы моңсу да аның, сөенечле дә, үтә сагышлы да. Татар халкы күп гасырлар дәвамында чамасыз авыр сынаулар кичерде, шулай да үз йөзен, үз телен, күңел бизәге булган үз гамен-ваемын югалтмады. Халкыбызның горурлыгын, намусын әнә шулар, М. Мәһдиевнең әсәрдән әсәргә күчеп килгән төрле-төрле характерлары, халык уллары саклап алып калды. Инде без үткән көннәр яңадан кабатланмас, кайбер бормалары кабатланса да, алары бүтәнчәрәк булыр»*.

Илнең рухи кризис кичерүе хакындагы уртак фикер әдәбиятта апокалипсиска бәйле темаларның барлыкка килүенә китерә (мәсәлән, бертуган Стругацкийларның «Град обречённых» (1988–1989) һәм В. Дудинцевның «Белые одежды» (1988) әсәрләре). Бу елларда инде онытыла барган язучыларның әсәрләрен дә яңадан бастыра башлыйлар. С. Липкин тарафыннан тәрҗемә ителгән «Идегәй» дастаны дөнья күрүгә, Г. Кандалый шигырьләренең академик басмасы нәшер ителүгә әдип чын күңелдән шатлана. 1987 елда ике театр сәхнәсендә режиссёрлар Марсель Сәлимҗанов һәм Фаил Ибраһимов сәхнәләштергән «Өч аршын җир» спектакленең премьералары исә А. Гыйләҗевнең үзе өчен дә, республикабыз иҗтимагый тормышында да зур вакыйга була. Чирек гасырдан соң тамашачыларга килеп ирешкән бу әсәр татар театры тарихында тирән эз калдыра һәм үзгәрешләр чорының үзенчәлекле символы, татар крестьяны язмышына «реквием» буларак кабул ителә.

Советларга каршы әсәрләр булып саналган күп кенә китаплар да, ниһаять, укучылар кулына килеп керә. Алар арасында А. Ахматованың «Реквием» поэмасын (Октябрь. – 1987. – № 3), Ю. Домбровскийның «Факультет ненужных вещей» әсәрен (Новый мир. – 1988. – № 8–11), В. Гроссманның «Жизнь и судьба» романын (Октябрь. – 1988. – № 1–4) һәм «Всё течёт» повестен (Октябрь. – 1989. – № 6), Б. Пастернакның «Доктор Живаго» романын (Новый мир. – 1988. – № 1–4) атап үтү урынлы булыр.

А. Солженицынның «Жить не по лжи» (Двадцатый век и мир. – 1989. – № 2), «Матрёнин двор» (Огонёк. – 1989. – № 23, 24), «Архипелаг ГУЛАГ» («Новый мир» журналында 1989 елның августыннан бирле басыла) әсәрләре исә көтелгән реакция уятмый, дискуссияләр тудырмый, чөнки интеллигенция ул вакытта А. Солженицынның «самиздат» яки «тамиздат» (рәсми рәвештә теркәлмәгән, хакимият һәм цензура тарафыннан тикшерелмәгән) басмаларын укып өлгергән була инде.

---

* А. Гыйләҗевнең шәхси архивы: «Сайланып чыккан сүзләр» (1989. – Июнь).